Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Кляшевская начальная общеобразовательная школа – детский сад»
Тетюшского муниципального района РТ

«Утверждаю»
Директор _____________/С.И.Бурганова/
от «____»________________2023 г.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 157D1A83037354A4EFFA6819895906F2
Владелец: БУРГАНОВА САНИЯ ИБРАГИМОВНА
Действителен с 07.04.2023 до 30.06.2024

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
учебного предмета **«Родной (татарский) язык»** 4 класс

Хамидуллина Гульшат Ахметовна,
учитель начальных классов
первой квалификационной категории

Принято на заседании
педагогического совета
протокол №1
от «      » августа 2023 года

2023 год

Сыйныф: 4
Программа материалы үтү өчен-102 сәгать
Атналык сәгатьләр саны:3

# Аңлатма язуы

**4 нче сыйныф өчен татар теле фәненнән эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:**

1. РФ һәм ТР "Мәгариф турындагы Закон" ына;

2.. Приказ 09.07.2012 №4154/12 "Об утверждении базисного и примерных учебных планов, для образовательных учреждении РТ, реализующих программы начального общего образования.;

3. Информационное письмо МО и Н РТ от 23 июня 2012 года №7699/12 « Об учебных планах для 1-9 классов школ РТ реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования с ФГОС общего образования «( 4 модель)

4. 06.10.2009 нчы елда РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган "Гомуми башлангыч белем бирү федераль дәүләт стандартын гамәлгә кертү" турындагы боерыгына (Приказ №373);

5. Белем бирү учреждениеләрендә укыту процессында куллану өчен рөхсәт ителгән "Перспективалы башлангыч мәктәп" концепциясе һәм белем бирүнең яңа стандартлары таләпләренә туры килгән һәм рөхсәт ителгән региональ дәреслекләргә

- Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән дәреслек "Перспективалы башлангыч мәктәп" И.Х.Мияссарова, К.Ф Фәйзрахманова .

**Татар теле фәнен тематик планлаштыруга аңлатма язуы.**



Документ создан в электронной форме. № 15уч2023 от 15.09.2023. Исполнитель: Бурганова С.И.
Страница 2 из 22. Страница создана: 15.09.2023 09:18
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Башлангыч гомуми белем бирүнең төп программасы федералж дәүләт белес стандартларын (Россия Федераөиясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, № 373, 06.10.2009) аныклаучы һәм үстереп җибәрүче норматив документ булып тора.**

***Эш программасы структурасы***. Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

***Эш программасының эчтәлеге.*** Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш"**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Татар теле укытуның **максаты: белемнәрне системага салу, тирәнәйтү, яңа мәгълүмат бирү, укучыларда әйтмә һәм язма сөйләмнәрен үстерү.**

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.**

**Тыңлап аңлау.** Сөйләмдәге сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аңлау, аларны бер-берсеннән аеру. әйтелгән фикердәге мөһимрәк булган вакыйгаларың эзлеклелегенә төшенү.Тыңлый белүне уңышлы аралашуның шарты, кара-каршы сөйләшүнең нигезе икәнен үзләштерү.

**Сөйләү.** Сөйләм культурасын үстерү. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен гамәли үзләштерү. Укуга һәм көндәлек тормышка кагылышлы темалар буенча әңгәмә кору.Укылган текстка сорау кую, аның эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирү, планын төзү. Укучыларга якынрак булган темалар буенча сөйләшү. Гадирәк җөмләләрдән төзелгән төрле темаларга кагылышлы монологик сөйләм оештыра белү, интонация үзенчәлекләрен үзләштерү. Сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану.

**Уку.** Әкиятләрне, кечкенә хикәяләрне, дәреслектәге текстларны аңлап, дөрес, йөгерек итеп укый белү. Текстның төп фикерен аңлап, темасын билгели алу, кирәкле урыннарын сайлап уку. Гади план төзеп, текстның эчтәлеген сөйләү һәм укучының текстка мөнәсәбәтен белдерү.Укыганның эчтәлегенә, тел үзенчәлекләренә, төзелешенә бәя бирү. Информацияне аңлата һәм гомумиләштерә алу.

**Язу.** Язма сөйләм белән телдән сөйләмнең аермасы. Җөмләне тексттан аера белү. Хат һәм төрле котлау текстлары язу. Өйрәнелгән кагыйдәләргә нигезләнеп текстларны күчереп, ишетеп язу.Үзлегеннән зур булмаган текстлар иҗат итү.

**Программа атнага 3 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 102 сәгать. Шулардан контроль диктантлар – 4 ,сочинение- 4, изложение – 4 сәгать.** Татар теленнән тематик план Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән дәреслек "Перспективалы башлангыч мәктәбе" И.Х.Мияссарова, К.Ф Фәйзрахманова нигезендә төзелде .



Документ создан в электронной форме. № 15уч2023 от 15.09.2023. Исполнитель: Бурганова С.И.
Страница 3 из 22. Страница создана: 15.09.2023 09:18
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**Укыту курсы темалары эчтәлеге:**

**1.1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.**

Аваз һәм хәреф. Сузык һәм тартык авазлар.Ижек.Сүзләрне юлдан юлга күчерү. ь,ъ хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Янәшә килгән бертөрле аваз хәрефләре булган сүзләр.Алфавит. Алфавитның әһәмияте.Сүзлекләр белән эш.Сингармонизм законы турында беренче күзаллау.

**2. Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе .**

Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Тотрыклы сүзтезмәләр, омоним, синоним антоним,фразеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эш. Күп мәгнәле сүзләр. Искергән һәм яңа сүзләр

**3. Сүз төзелеше.**

Кушымча.Кушымчаларның төрләре.Кушымчаларның ясагыч һәм төрләндергеч буенча ясалышы(кушма, парлы сүзләр)

**4. Сүз төркемнәре . Исем.**

Исем. Мәгънәсе, сораулары. Җөмләдәге роле Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр Ялгызлык исемнәрдә баш хәреф

Берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше.

**5. Фигыль .**

Мәгънәсе. Сораулары. Барлык, юклык формалары Зат-сан белән төрләнүе. Хәзерге, үткән, киләчәк заманнар. Фигыльләрнең күп мәгънәлеге.

Боерык фигыль. Фигыльнең нигезе дифтонгка тәмамлануы. (сау-савыйм, савыйк, савыгыз)

**6. Сыйфат .**

Мәгънәсе,сораулары. Җөмләдә роле. Сөйләмдә әһәмияте. Сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатның җөмләдәге роле. (аергыч, хәбәр)

**7. Алмашлык ..**Зат алмашлыклары. Җөмләдәге һәм текстагы роле. Сорау алмашлыклары.Килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы.

**8. Сан .**

Санның билгеләмәсе, сорауларымикдар саны, тәртип саны.

**9. Рәвеш .**Лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен белдерүе.Аның төрләнмәве.Төп синтаксик функциясе – хәл.

**10. Кисәкчәләр.** Да. дә. гына , генә. Та, тә, ук, үк, кына ,кенә кисәкчәләре. Сөйләмдәге роле. Аларның җөмләгә төрле төсмер өстәве.

**11. Бәйлекләр .** Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә йомгак ясау, системалаштыру.

**12. Җөмлә. Сүзтезмә .**

Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәдәге ияручe һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү

**13. Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр.**

Җөмләнең баш кисәкләре.

**14. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.** Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру.



Документ создан в электронной форме. № 15уч2023 от 15.09.2023. Исполнитель: Бурганова С.И.
Страница 4 из 22. Страница создана: 15.09.2023 09:18
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

**15. Җөмләнең иярчен кисәкләре Аергыч .** Аергычка билгеләмәне һәм аның белдерүен аңлату.

**16. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.**

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең узара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнеше.Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

**17 .Эндәш сүзләр.** Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре.

**18. Гади һәм кушма җөмлә.**

Тезмә кушма җөмләләрдә һәм, ә, ләкин, әмма теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре.

## Укучыларның белем һәм күнекмәләренә төп таләпләр

### Укучылар белергә тиеш:

-сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча, төрләндергеч кушымча;

- сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек, рәвеш.
- җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, җөмләнең иярчен кисәкләре

**Укучылар башкара алырга тиеш:**

-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 75-80 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп диктант итеп язу.

-текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу.

- сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү(тамыр һәм кушымчаларны аеру, кушымчаларның төрен билгеләү, тамыр, ясалма, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү).
- сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
- берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү
- фигыльне заман формаларына куя белү.

-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү.

-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру; сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне аеру.

- җөмлә тикшерү (төрен билгеләү, баш һәм иярчен кисәкләрне аера белү)
- бергәләп төзегән план буенча 90-95 сүзле изложение язу.
- текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, кызыл юлны саклау.
- текстның мәгънәле кисәкләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.



Документ создан в электронной форме. № 15уч2023 от 15.09.2023. Исполнитель: Бурганова С.И.
Страница 5 из 22. Страница создана: 15.09.2023 09:18

ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), сочинение язу.
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**4 нче сыйныф ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру программасын үзләштерү буенча планлаштырыла торган нәтиҗәләр**

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда белем алу осталыгы нигезе буларак **танып белү, коммуникатив, регулятив һәм шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашачак.**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
• күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;
• тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
• материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
• бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
• фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
• уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

• *интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;*
• *мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;*
• *сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү тө-зергә.*

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
• нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
• килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
• сораулар формалаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

• *сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;*
• *монолог төзергә.*

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

• таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерегә;
• гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
• кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
• максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.

*Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:*

• *партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;*



Документ создан в электронной форме. № 15уч2023 от 15.09.2023. Исполнитель: Бурганова С.И.
Страница 6 из 22. Страница создана: 15.09.2023 09:18
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

• *уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;*
• *ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;*
• *яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.*

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре**

Укучыларда формалашачак:

• татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
• дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
• үз уңышларын/уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
• нормалардан тайпылышны күрү;

**ШУУГ- шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәллә**

**ТБУУГ- танып белү универсаль уку гамәлләре РУУГ-**

**регулятив универсаль уку гамәлләре**

**КУУГ- коммуникатив универсаль уку гамәлләр**

**Татар теленнән календарь – тематик план 4 класс**

| № | Дәреснең темасы | Сәг | Үтәлү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | фа кт |
| 1 | 2 | 3 | 8 | 9 |
| 1 | 1-3 нче сыйныфлардаүткәннәрне кабатлау. | 1 | 3.09 | |
| 2 | Җәйге истәлекләр буенча сочинение язу. | 1 | 5.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Авазлар һәмхәрефләр. | 1 | 8 .09 | |
| 4 | Грамматик биремле диктант<br>.Күбәләк малае Әлтәфи. | 1 | 10.09 | |
| 5 | Тамыр һәм<br>кушымча | 1 | 12.09 | |
| 6 | Сүз төркемнәре | | 15 .09 | |
| 7 | 1-3 сыйныфта үткәннәр буенчатест биреме №1 | 1 | 17 .09 | |
| 8 | Аңлатмалыдиктант.<br>Көз якынлаша. | 1 | 19 .09 | |
| 9 | **Сүзнең лексикмәгънәсе** | 1 | 22.09 | |
| 10 | Алынма сүзләр. | 1 | 24.09 | |
| 11 | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. | 1 | 26.0.9 | |
| 12 | Тотрыклы<br>сүзтезмәләр. | 1 | 29. 09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 13 | Омонимнар | 1 | 1.10 | |
| 14 | Синонимнар,антонимнар. | 1 | 3.10 | |
| 15 | Изложение язу.Усак. | 1 | 6.10 | |
| 16 | **Сүзнең лексик мәгънәсе** темасыбуенча тест биреме №2 | 1 | 8.10 | |
| 17 | Тамыр һәмкушымча. | 1 | 10.10 | |
| 18 | Сүз ясагыч кушымчалар. | 1 | 13 .10 | |
| 19 | Сүз ясагыч кушымчалар. | 1 | 15.10 | |
| 20 | Сюжетлы рәсем буенча сочинение.”Җиләкле җәй” | 1 | 17. 10 | |
| 21 | Төрләндергечкушымчалар. | 1 | 20 .10 | |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 22 | Кушма сүзләр. | 1 | 22.10 | |
| 23 | Кушма сүзләр. | 1 | 24.10 | |
| 24 | Парлы сүзләр. | 1 | 27.10 | |
| 25 | Тезмә сүзләр. | 1 | 7.11 | |
| 26 | **Контроль диктант №1“Хәлимә”** | 1 | 10.11 | |
| 27 | Хаталар өстендә эш.Үткәннәрне ныгыту.Тест №3 | 1 | 12.11 | |
| 28 | Сүз төркемнәре. Исем. | 1 | 14.11 | |
| 29 | Ялгызлык һәмуртаклык исемнәр. | 1 | 17.11 | |
| 30 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | | 19.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | диктант. | | | |
| 31 | Берлек һәм күплек сандагыисемнәр. | 1 | 21.11 | |
| 32 | Исемнәрнеңкилеш белән төрләнеше. | 1 | 24.11 | |
| 33 | Исемнәрнең килеш һәм тартымбелән төрләнеше | 1 | 26.11 | |
| 34 | Исемнәрнең килеш һәм тартымбелән төрләнеше.Тест | 1 | 28.11 | |
| 35 | Контроль диктант"Хәлимә" | 1 | 1.12 | |
| 36 | Фигыль турындаүткәннәрне искәтөшерү. | 1 | 3.12 | |
| 37 | Хәзерге заманхикәя фигыль. | 1 | 5.12 | |
| 38 | Хәзерге заманхикәя фигыль. | 1 | 8.12 | |
| 39 | Үткән заманхикәя фигыль. | 1 | 10.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 40 | Үткән заманхикәя фигыль. | 1 | 12.12 | |
| 41 | Киләчәк заманхикәя фигыль. | 1 | 15.12 | |
| 42 | Киләчәк заманхикәя фигыль. | 1 | 17.12 | |
| 43 | Боерык фигыль. | 1 | 19.12 | |
| 44 | Боерык фигыльнең төрләнеше. | 1 | 22.12 | |
| 45 | Боерык фигыль. | 1 | 24.12 | |
| 46 | Антоним һәмсиноним фигыльләр. | 1 | 26.12 | |
| 47 | **Контроль диктант. “Төлке”** | | 9.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 48 | Хаталар өстендәэш. Тест биремнәрен башкару. | | 12.1 | |
| 49 | Сыйфат турындаүткәннәрне кабатлау. (2кисәк) | 1 | 14.1 | |
| 50 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 1 | 16.1 | |
| 51 | Сыйфат дәрәҗәләре. | 1 | 19.1 | |
| 52 | Сыйфатларның җөмләдә аергычһәм хәбәр булып килүе. | 1 | 21.1 | |
| 53 | Синоним һәмантоним сыйфатлар. | 1 | 23.1 | |
| 54 | Сочинение язу "Керпе". | 1 | 26.1 | |
| 55 | Үткәннәрне ныгыту.Тест биреме. | 1 | 28.1 | |
| 56 | Зат алмашлыклары. | 1 | 30.1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 57 | Зат алмашлыкларыны<br>ң килеш беләнтөрләнеше. | 1 | 2.2 | |
| 58 | Зат алмашлыкларының килеш белән<br>төрләнеше. | 1 | 4.2 | |
| 59 | Сорау алмашлыклары. | 1 | 6.2 | |
| 60 | Сорау алмашлыклары.Тест биремнәре. | 1 | 9.2 | |
| 61 | Аңлатмалы диктант “Анығәркем ярата” | 1 | 11.2 | |
| 62 | Сан турындатөшенчә. | 1 | 13.2 | |
| 63 | Микъдар саны. | 1 | 16.2 | |
| 64 | Микъдар саны. | 1 | 18.2 | |
| 65 | Тәртип саннары. | | 20.2 | |
| 66 | Тәртип саннары.Тест | 1 | 25.2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | биремнәре. | | | |
| 67 | Искәртмәле диктант." Чәүкә" | 1 | 27.2 | |
| 68 | Рәвеш турындатөшенчә. | **1** | 2.3 | |
| 69 | Те лдә еш кулланыла торганрәвешләр, аларның дөрес язылышы. | 1 | 4.3 | |
| 70 | Телдә еш кулланыла торганрәвешләр, аларның дөрес язылышы. | 1 | 6.3 | |
| 71 | Изложение язу “Ябалак, тавык, аучы” | 1 | 9.3 | |
| 72 | Рәвеш темасынныгыту.Тест биреме. | 1 | 11.3 | |
| 73 | Кисәкчәләр. | 1 | 13.3 | |
| 74 | Кисәкчәләрнең сөйләмдә роле.Тест биреме. | 1 | 16.3 | |
| 75 | Бәйлекләр. | 1 | 18.3 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 76 | Бәйлекләр. | 1 | 20.3 | |
| 77 | **Контроль диктант №3 “Сугыш һәм яз**” | 1 | 23.04 | |
| 78 | Хаталар өстендә эш.Бәйлек темасын ныгыту. | 1 | 3.4 | |
| 79 | Сүзтезмә. | 1 | 6.4 | |
| 80 | Сүзтезмәдә сүзләрбәйләнеше.Аңлат малы диктант. | 1 | 8.4 | |
| 81 | Җөмлә.Җөмләнеңбаш кисәкләре**.** | 1 | 10.4 | |
| 82 | Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр. | 1 | 13.4 | |
| 83 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. | | 15.4 | |
| 84 | Җөмләнең иярченкисәкләре.Аергыч<br>. | 1 | 17.4 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 85 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. | 1 | 20.4 | |
| 86 | Эндәш сүзләр.Тест биреме. | 1 | 22.4 | |
| 87 | Гади һәм кушма җөмлә. | 1 | 24.4 | |
| 88 | Гади һәм кушма җөмлә. | 1 | 27.4 | |
| 89 | **Изложение язу.“Кечкенә умартачы”** | 1 | 29.4 | |
| 90 | Үткәннәрне ныгыту.Тестбиремнәре. | 1 | 1.5 | |
| 91 | Текст.Тема.Текстөлешләре. | 1 | 4.5 | |
| 92 | Текст.Тема.Текстөлешләре. | 1 | 6.5 | |
| 93 | Сөйләм этикасы. | 1 | 8.5 | |
| 94 | Сөйләм этикасы. | 1 | 11.5 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 95 | Хикәяләү, тасвирлау текстлары. | 1 | 13.5 | |
| 96 | Хикәяләү, фикерләү текстлары. | 1 | 15.5 | |
| 97 | **Контроль диктант №4 “Җырчы кош”** | 1 | 18.5 | |
| 98 | Хаталар өстендә эш. Сурәтләү һәмхикәяләү текстлары | 1 | 20.5 | |
| 99 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту. | | 22.5 | |
| 100 | Үткәнне ныгыту | 1 | 25.5 | |
| 101 | Уку елында өйрәнгәннәрненыгыту .Тест биремнәре | 1 | 27.5 | |
| 102 | Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту.Йомгак. | 1 | 29.5 | |

**4 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр**

-сүзләрдәге орфограммаларны танып, аларның язылышын кагыйдәгә нигезләнеп аңлату;

-үтелгән орфограммалар кергән 75-80 сүзле текстны хатасыз, каллиграфик күчереп һәм ишетеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;

-*дөнья, болыт* тибындагы сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау;

-сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү: тамырын һәм кушымчасын табу, кушымчаларның төрен билгеләү, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү;

-сүзләрне сүз төркеме булу ягыннан тикшерү: исемнең сан, килеш формасын күрсәтү; сыйфатның асыл, нисби төрен, чагыштыру дәрәҗәсен билгеләү; фигыльнең зат-сан, заманын аера белү; һәр сүз төркеменең җөмләдәге функциясен билгеләү;

-тиңдәшле кисәкле гади җөмләгә, составында 2-3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләгә анализ ясау;

-җөмләләрнең әйтелү максаты, интонациясе буенча төрен аеру;

-текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, шулар нигезендә аңа килешле исем кую;

-хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү тибындагы текстларны сөйләмдә куллану;

-әдәпле мөгаләмә таләпләренә туры китереп аралаша белү;

-тасвирлау, фикер йөртү элементлары кергән 90-95 сүзле текстны изложение итеп язу;

-хикәяләү тибындагы сочинение язу;

-сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: *авыру, аз-маз,ата-ана,ашханә, аңлый,әби-бабай, әверелә, әүвәл,балачак, бәла, берничә, борынгы, вакыйга, ватык, гадәт, гомер, дәвам, җәяү, җепшек, җиләк-җимеш, зинһар,иелә, ихтирам, йомры, кадәр, киемсалым, кулъязма, көнбатыш, көнчыгыш, көрәшче, кыйммәтле, мал-туар, мәйдан, мәкалә, могҗиза, мөстәкыйль, нәкъ,охшаш, очсыз, өем, өчпочмак, пәрәвез, рәссам, савыт-саба, сәнгать, сөңге, сурәт, табиб, табигый, таләп, тәкъдим, тәмам, тирә-як, төер, туп-туры, тынгылык, чүп-чар, шагыйрь, шәфәкъ, шыңшый, эшчән, юеш, юньле, юучы, ямьле, ямь-яшел, япь-яшь*

***Укучыларның белемен бәяләү системасы***

Укучыларның эшчәнлеген бәяләү белемнәрне үзләштерүне тикшерүдәе аларны гамәлдә куллана белүгә күчерелә.

*Мәгълүмат чыганаклары*:

-укучыларның эшләре

-танып белү процессының барышы;

-статистикага нигезләнгән мәгълумат;

-тестлар уздыру нәтиҗәләре;

-портфолио;

*Тикшерү алымнары:*

-күзәтүләр;

-мөстәкыйль контроль эшләр;

-укучыларның әзер җавапны табуы, ирекле кыскача җаваплары; ачык җавап, үз-үзеңне тикшерүх өчен сораулар куя белү.

*Бәяләү критерийлары:*

--җавапларның дөрес булуы;

-грамматика кагыйдәләрен куллана белүдә шәхси үсеш;

-әйтмә һәм язма сөйләмнең төгәллеге һәм сәнгатьлелеге үсешендә югарырак баскычка күтәрелү;

-җавапның, уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән продуктның сыйфаты; нигезләмәләрнең уйланган булуы;мөстәкыйль әйтелгәнгипотезаның, аңлатмаларның, язма сөйләм модельләренең дөрес төзелгән булуы, сөйләмнең максатчан оештырылуы.

***Уку әсбабы***

1. Татар теле 1 кисәк, 2 кисәк дәреслек 4 сыйныф И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова “Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел
2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова Методик әсбаб. “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел

3. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар. 1-11 нче сыйныфлар Казан Татар.китап. нәшрияты 2011 ел

4. Диктантлар җыентыгы

5. 1-4 сыйныфлар өчен язма эшләр Казан 2009

Лист согласования к документу № 15уч2023 от 15.09.2023
Инициатор согласования: Бурганова С.И. Директор
Согласование инициировано: 15.09.2023 09:18

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Бурганова С.И. | | Подписано 15.09.2023 - 09:18 | - |